| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НОРЛАТ АВЫЛЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«01» декабрь 2024 ел

КАРАР
№23

Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 01 сентябрендәге 24 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 стаьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 01 сентябрендәге 24 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 пунктның «б» пунктчасының алтынчы абзацында «тапшыру» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә.

1.2. 5 пунктның «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү;

бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгеләү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы» үзәге бинасы)   урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

И.М.Саттаров